Рус мәктәбенең татар төркемендә укучы балалар өчен
татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре

10 нчы сыйныф
Үткәрү вакыты 180 мин.

I. ТЕСТ:

Дөрес җаваплярны билгеләгез: (1әр балл)

1. “Кыйссаи Йосыф ” (Кол Гали) поэмасының төп геройларының исемнәрен аларга хас сыйфатлар турысында языгыз.

а) гадел, тыйнык, акыллы - _____
ә) саран, көнчел, әдәпсез - _____
б) матур, җиңел акыллы, максатчан - _____

2. “Сәхипҗамал” (Г.Кандалый) кайсы чорда ижат ителә:

а) Казан ханлыгы чорында
ә) Алтын Урда чорында
б) XIX йөздә

3. С.Рәмиевнең әсәрен билгеләгез:

а) “Каләмгә хитаб”
б) “Авыл”
в) “Мәхәббәт”

4. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының чорларга бүленеше: (1әр балл)

1) _____
2) _____
3) _____
4) _____
5) _____
6)_____

II. БИРЕМНӘР:

1. **К.Тинчуринның тормыш юлы һәм ижаты турында белгәннәрегезне языгыз, бер драма әсәрен анализлагыз** (10 балл).

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

2. **Троп төшенчәсенә билгеләмә бирегез. Тропларга мисаллар языгыз.** (8 балл).

3. Бу юллар кайсы әсәрдән? Авторын, әсәрнең исемен, жанрын языгыз. Төп геройларны характерлагыз. (8 балл).

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан 8 ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», - дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек! Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да, сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

4. Бирелгән сүзләрдән билгеле шигырь юлларын төзегез, шигырьнең авторы кем булуын языгыз; шигырьдә бирелгән хис-тойгыны билгеләгез. (8 балл).

Ул, ләкин, һәрбер, яшьлек, мәхәббәт, белән, янарга, аны, үзе, иске, яңарта, нәрсә, тиле, йөрәк, хисе, аның, ярты, бирә, гомрен...

Барлыгы 45 балл